СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
“27” февраль 2023 ел

КАРАР
№ 87

2018 елның 25 декабрендәге 138 номерлы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында «Татарстан Республикасы Чепья авыл җирлеге башлыгының, Чепья авыл жирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәт өчен түләү тәртибе турында»

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру”турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августы 881 нче карары һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләрнең,рәис урынбасарларының,муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» гы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне билгеләү турында»гы 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына(01.11.2018 ,№152, 09.10.2020 №11, 18.01.2022 №101, 25.02.2022 №109 үзгәрешләр белән)үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2022 елның 13 октябрендәге 144 нче номерлы карары һәм Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл

җирлеге башлыгы,Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәт өчен түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 138 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында «11 163» санын «18 652» санына алмаштырырга;

1.2. Карарның 1нче кушымтасында «16 750» санын «19 039» санына алмаштырырга ;

1.3. Карарның 3 нче кушымтасының 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;
1.4. Карарларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Муниципаль хезмәткәрләрнең гомуми хезмәт хакы муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан (алга таба - вазыйфаи оклад), сыйныф чины өчен айлык өстәмә түләү,тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү, муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен өстәмә түләү, айлык акчалата бүләкләү, норматив булмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр, еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү һәм матди ярдәмнән гыйбарәт.»;

2. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында: baltasi.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы: pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

6. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Чепья авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Нотфуллин